Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

28 гыйнвар 2020 ел № 89

«Яңа Елховой нефть ятмаларының
өстәмә скважиналарын төзекләндерү.
7 этап» объекты өчен территорияне
планлаштыру проектын һәм ызанлау
проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Нефтехимпроект» акционер җәмгыяте мөрәҗәгате нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районының Әлмәт, Аппак, Бута, Кичү, Рус Акташы авыл җирлекләре территорияләре буйлап уза торган «Яңа Елховой нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» объекты өчен «Нефтехимпроект» акционерлык җәмгыятенә үз акчалары исәбеннән территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.


4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

.
Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«28» гыйнвар № 89 карарына
1 нче кушымта

Яңа Елховой нефть ятмаларының өстәмә скважиналарын төзекләндерү. 7 этап» объекты өчен территория чикләре




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косарев